| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.05.2016 Казан ш. № 10-7/кс

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының «2016-2018 елларга эчергә яраклы суга, техник суга, техник суга, су бүлүгә, салкын суны транспортировкалауга һәм ташландык суларны транспортировкалауга тарифлар билгеләү турында»гы 2015 елның 27 ноябрендәге 10-32/кс санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законга, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны исәпләп чыгару буенча Методик күрсәтмәләрне раслау турында» тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2013 елның 27 декабрендәге № 1746-э санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп һәм «Азнакай җылылк челтәрләре оешмасы» ачык акционерлар җәмгыяте 2016 елның 16 маендагы 636 санлы хатына нигезләнеп Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының «2016-2018 елларга эчергә яраклы суга, техник суга, техник суга, су бүлүгә, салкын суны транспортировкалауга һәм ташландык суларны транспортировкалауга тарифлар билгеләү турында»гы 2015 елның 27 ноябрендәге 10-32/кс санлы карарына үзгәрешләр кертергә:

1 кушымтаның 2.1 пунктындагы «Азнакай шәһәре кулланучылары» сүзләрен «Азнакай шәһәре Балтач авыл җирлеге кулланучылары» сүзләренә үзгәртергә;

1 кушымтаның 2.2 пунктындагы «Ак түбә шәһәр тибынадагы поселогы кулланучылары» сүзләрен «Микулин авыл җирлеге Ак түбә шәһәр тибынадагы поселогы кулланучылары» сүзләренә үзгәртергә;

2 кушымтаның 2.1 пунктындагы «Азнакай шәһәре кулланучылары» сүзләрен «Азнакай шәһәре Балтач авыл җирлеге кулланучылары» сүзләренә үзгәртергә;

2 кушымтаның 2.2 пуктындагы «Ак түбә шәһәр тибынадагы поселогы кулланучылары» сүзләрен «Микулин авыл җирлеге Ак түбә шәһәр тибынадагы поселогы кулланучылары» сүзләренә үзгәртергә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов